ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕСУБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«28» апрель 2023г.** **№60**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Гамәлдәге законнар үзгәрү белән бәйле рәвештә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Югары Субаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып:

1. Үз көчен югалткан дип таныргa:
1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль үткәргәндә тикшерүләр үткәрү функциясен үтәү буенча административ регламентны раслау турында «30.04.2013 № 9 карарын.
1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында»2013 елның 14 мартындагы 3 номерлы карары.
1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль үткәргәндә тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 17 октябрендәге 12 номерлы карары.

1.4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында»21.04.2011 № 11 карары.
1.5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә терегөмөшле лампаларны беренчел җыю һәм вакытлыча урнаштыру урынын билгеләү турында»24.12.2021 №21 карары.
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы А. А. Хөснетдинов